ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

04.08.2026 **г.Чистополь** **№** 328

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 584 номерлы карары белән расланган мәгълүмати вывеска урнаштыру, вывеска урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Мәгълүмати вывеска урнаштыру, вывеска урнаштыру дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары белән расланган дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә гарызнамәләрне тутыру кагыйдәләренең 13 пункты таләпләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 584 номерлы карары белән расланган мәгълүмати вывеска урнаштыру, вывеска урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» 3 бүлегенең 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгеле торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов